**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидо авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**19 сентябрь 2019 ел** **№ 122**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге территориясендә гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү һәм үткәрү турында**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында”гы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы “Җирле референдум турында”гы Татарстан Республикасы Законының 18 маддәсе, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Уставының 15 маддәсе, 2019 елның 19 сентябрендәге ___ номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. 2019 елның 17 ноябренә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, биш һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләр, көндезге формада укучы студентлар), җирлек территориясендә яшәүче 18 яшькә җиткән тавыш бирү хокукына ия булган һәр гражданнан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге

эшләрне башкару буенча 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:
- поселок эчендәге һәм урамара юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- суүткәргеч һәм су чыганакларын ремонтлау;
- чүп җыю һәм чыгару.

3. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:
ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Красновидово авылы, Совет урамы, 4 йорт;
ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Бортас авылы, Үзәк урам, 3 йорт;
ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Антоновка авылы,
шулай ук “Волжские зори” (“Идел таннары”) газетасының рәсми сайтында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Красновидово авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **В. П. Оленин**